СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

24 сентябрь, 1997 ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 107 (8119) | Бәясе билгеләнгәнчә

## КҮПКӘ ТЫРЫШКАННЫ АЗГА ДА ТҮЗСӘК

### Район семинар - киңәшмәсеннән

Игенчеләребез төп уракны республикада иң алдан төгәлләделәр, дәүләткә иң күп һәм иң яхшы сыйфатлы бодай тапшырдылар. Дүшәмбе көнне хуҗалык җитәкчеләре, авыл хуҗалыгына хезмәт күрсәтүче предприятиеләр һәм оешмалар, аерым бер







службалар башлыклары катнашында узган семинар - киңәшмәне ачканда хакимият башлыгы Ф.С.Сибагатуллин моны зур горурлык белән билгеләп үтте һәм уракны шулай оешкан төстә башкарып чыгуга катнашы булган пәркемгә олы рәхмәтен белдерде. Әмма эшнең алда торганнары да шактый ук әле. Шулардан иң мөһимнәре - кукурузны җыеп алып урнаштыру, туңга сөрүне ничек тә тизрәк тәмамлау һәм шикәр чөгендере алуны шулай ук зур оешканлык белән башкарып чыгу. Бер үк вакытта уҗым чәчүлекләрен минераль ашлама белән тамырдан тукландыру һәм фундазол препараты белән эшкәртү дә мөһим. Терлекчелек өлкәсендә исә малларны абзарга кайтарып бетерү көнүзәк бурыч булып тора. Хакимият башлыгы семинар - киңәшмәдә катнашучыларның игътибарын бу эшләрнең һәммәсе кичектергесез һәм мөһим булуына юнәлтте.

Малларга кыш буена җитәрлек мул һәм туклыклы концентрат азык запасы булсын дисәк, хәзер нәкъ менә өлгереп җиткән кукурузның чәкәннәрен җыеп алып эш итү мөһим. Семинар - киңәшмә узган Мичурин исемендәге хуҗалыкта аны КПГ- 3 агрегаты ярдәмендә җыеп алып, ИСУ аркылы ваклатып корнаж иттереп, тимер - бетон плитә белән эчләнгән базга салалар. Хуҗалыкның мөмкинлекләреннән һәм традицияләреннән чыгып кукурузны җыю һәм саклауның башка юлларын да кулланырга мөмкин, тик шулкадәр кыйммәтле азыкның кырда калмавы гына мөһим, чөнки бер килограммы өч килограмм арышны алыштыра торган бу корнажның дуңгызларга гына түгел, мөгезле эре терлекләргә дә бәяләп бетергесез азык булуы билгеле.

Туңга сөрүне дә ничек тә тизрәк тоту турында уйларга кирәк, чөнки көздән эшкәртелми калган җирдә уңышның ким дигәндә ун центнерга азрак булуы бәхәссез. Шуңа күрә туңга сөрүне ничек тә башкарып калдыру өчен бар көчне тупларга кирәк һәм бу эшне тынычлану өчен кеше күзе алдындагы урыннарда гына түгел, ә иң ерак басуларда да үткәрү турында уйларга кирәк. Өстәвенә, шикәр чөгендере чәчеләчәк җирләрне хәзердән раундап препараты белән эшкәртеп калдыру турында да уйлыйсы бар әле. Уҗым культуралары әйбәт кышласын, язын аларны сипләргә яки бозып чәчәргә үк туры килмәсен дисәк, аларны хәзердән минераль ашлама белән тукландырып һәм фундазол белән эшкәртеп калдыру мөһим. Беренчесе өчен ашлама «Агрохимсервис»та җитәрлек кадәр булса, икенчесен оешма заявка буенча үз техникасы белән уздыра ала.

Шикәр чөгенде казу һәм аны тапшыру турында сүз барышында хакимият башлыгы һәр хуҗалыкта бу культураны игүнең икътисадый яктан нәтиҗәлелеген кабат - кабат исәпләп карау кирәклеге турында да әйтеп үтте.

Терлекчелектә малларны абзарларга тиз арада кайтару зарурлыгын соңгы вакытта ешая башлаган яңгырлар ачык искәртә. Әмма кайбер хуҗалыкларда каралтыларны тулы әзерлеккә китерү өчен ашыгыч чаралар күрәсе бар әле. Ә инде терлек каралтыларын ничек иттереп үрнәк төстә әзерләү, малларны бәйләүсез асраугa көйләү мөмкинлекләрен семинарда катнашучылар «Киекле» хуҗалыгы товарлыклы - сөтчелек фермасында монтажланган швед сөт саву җайланмасы белән танышканда ачык күрделәр.

Семинар - киңәшмәдә агропромышленность комплексындагы эшләргә кагылышлы башка күп кенә мәсьәләләр дә кузгатылды. Хакимият башлыгы аерым алганда авылда реформалар уздыру эшен күз уңыннан читкә җибәрмәү, эшләүчеләр арасында хезмәт һәм башкару дисциплинасын, гомумән эштә тәртипне ныгыту, кадрларның тапшырылган эш өчен җаваплылыгын күтәрү аша авыл товар җитештерүчеләренең мөстәкыйльлеген үстерүгә юл тоту зарурлыгын ассызыклап үтте. Шул ук вакытта Ф.С.Сибагатуллин җитәкчеләрнең игътибарын хезмәт кешесе белән уртак тел табып, ачыктан - ачык сүз алып бару зарурлыгына юнәлтте.

**Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.**
**Н.АЗИЗОВ фотолары.**

**Ашлык - дәүләткә**

### Бодай булгач күмәч ашарбыз

**Дәүләт амбарларына саклауга бодай салу заданиесен уңышлы үтәп чыгучы хуҗалыклар сафы ишәйгәннән ишәя бара. «Киекле», Мичурин исемендәге, шикәр заводы ярдәмче хуҗалыгы, «Чирмешән», «Заветы Ильича» хуҗалыклары заданиедәге күләмдә яхшы сыйфатлы ашамлык бодае озаттылар.**

**«Рассвет» исә күтәренке заданиене бодай буенча да, тулаем да уңышлы башкарып чыккан икенче хуҗалык булды. Биредән дәүләт амбарларына 2674 тонна ашлык керде.**

## Котлау

***Халык депутатларының Октябрь район Советы, район хакимияте республика район газеталары һәм профессиональ осталык смотр - конкурсында беренче урынны яулаган «Дуслык» газетасы коллективын чын күңелдән котлый һәм киләчәктә дә иҗади уңышлар тели.***

## «Һөнәре буенча иң яхшы» - СИРЕНЬ РИЗАЕВА



**Район газетасы өчен сөенечле вакыйга турында хәбәрне укучыларыбызга җиткерүе күңелле: үткән атна ахырында Зәй шәһәрендә узган полиграфия осталагы республика смотр - конкурсында безнең «Дружба» газетасы электрон хәреф җыючысы Сирень Наил кызы Ризаева район газеталары вәкилләре арасында I урынга чыкты. Бу уңыш өчен Сирень «Һөнәре буенча иң яхшы» исеменә һәм приз - «Самсунг» телевизорына лаек булды.**

**Без коллегабызны зур җиңүе белән чын күңелдән котлыйбыз, аңа сәламәтлек, бәхет, яңа иҗади уңышлар телибез.**

* * *

**Шул ук смотр - конкурста линотипистлар ярышында Норлат шәһәр типографиясе машина белән хәреф җыю остасы Фидания Ислам кызы Хәйретдинова катнашып уңышлы чыгыш ясады.**

## Эш артыннан эш килә

### *«Уңыш - 97»*
### *матбугат үзәге хәбәр итә*

Хуҗалыкларда икенче урак темпы арта бара. Кичәге көнгә шикәр чөгендере 575 гектар мәйданнан казып алынды һәм шуның 110 гектары «Киекле» хуҗалыгы өлешенә туры килә. «Дуслык»та татлы тамырны барлык мәйданның өчтән береннән казып алдылар инде. «Рассвет» «Игенче» Кузнецов исемендәге, «Заветы Ильича», Хафизов исемендәге, «Кондырча» хуҗалыкларында да икенче уракта оешканлык күрсәтелә. Әмма МСО ярдәмче хуҗалыгында бу эшкә тотынмаганнар да әле, тагын берничә хуҗалыкта керешеп кенә киләләр.

Туңга сөрү планы 56 процентка үтәлеп, «Таң» һәм «Дуслык»та бу күрсәткеч 76 - 78, Мичурин исемендәге хуҗалыкта 70, Синдряков исемендәге, «Киекле», «Рассвет», М.Җәлил исемендәге хуҗалыкларда 65 - 69 процент тәшкил иткән бер вакытта шикәр заводы ярдәмче хуҗалыгында һәм «Комбайн»да 34 - 35 процент кына әле.

## Сайлау нәтиҗәләре

1997 елның 20 сентябрендә 13 номерлы Дальний сайлау округы буенча халык депутатларының район Советына депутат сайлау үтте. Әлеге округ буенча депутат итеп 1966 елда туган, халык депутатларының Октябрь район Советы рәисе урынбасары вазифаларын башкаручы, хакимият башлыгының Советлар белән эшләү буенча киңәшчесе **Ельченков Андрей Николаевич** сайланды.

Район сайлау комиссиясе хәбәр итүенчә, тавыш бирү исемлегенә 1804 сайлаучы кертелгән. Кандидатны яклап 1682, аңа каршы 7 сайлаучы тавыш биргән, гамәлгә яраксыз дип табылган бюллетеньнәр юк.

## Мәктәптә ЧП

**1997 елның 22 сентябрендә Норлатның 4 нче мәктәбендә зур җәмәгатьчелек резонансы уяткан ЧП булды. Иртәнге сәгать 10 нар тирәсендә тәнәфес вакытында югары класс укучысы И. шул ук мәктәпнең 11 класс укучысы И.Идрисовка пычак белән 5 җәрәхәт ясаган. Алынган җәрәхәтләр нәтиҗәсендә соңгысы үлгән. Октябрь районы прокуратурасы хәбәр итүенчә, бу эш буенча беренчел тикшерү бара, аның нәтиҗәләре турында өстәмә хәбәр ителер.**

**Район мәгариф бүлеге администрациясе әлеге факт буенча мәктәп җитәкчелегенә карата тиешле тәэсир итү чараларын күрә.**

# Алай түгел, болай ул, арпа түгел, бодай ул



**_Быел районыбыз кырларында ишелеп үскән мул иген уңышының шактый өлеше ашамлык бодае булуы куанычлы. Ник дигәндә, бодай - бездә игелә торган культуралар арасында әлегә иң кыйммәтлеләреннән. Шуңа күрә дә быел бодай чәчүлекләре мәйданнары да гадәттәгедән шактый киңәйтелде, ул кырларга игътибар да зур булды. Һәм моның нәтиҗәсе күзгә күренерлек чыкты: бодайның гектарыннан уртача 48 центнер уңыш җыеп алынды һәм бу аны дәүләт амбарларына да гомер булмаган күләмдә - 55 мең тоннага якын салырга мөмкинлек бирде. Кара исәп белән генә санаганда да бу 47 миллиард сумлык дигән сүз._**

**_Кара исәп белән дип бодайның сортын - мазарын исәпкә алып тормыйча, сыйфатын уртача гына исәпләп санау турында әйтүебез. Әмма әле аның сортлылык, сыйфат күрсәткечләрен дә күз уңында тотып эш итсәң, тапшырылган бодайның әҗере дә шактый саллырак булырга мөмкин. «Татарстан кыры фәнни җитештерү берләшмәсенең «Ашамлык бодае» төркеме җитәкчесе И.Ф.ЛЕВИН белән әңгәмәбез дә шул хакта._**

**- Иосиф Фомич, әле кыш көне үк районда республиканың бер төркем галимнәре катнашында уздырылган семинар - укуларда Сез ашамлык бодае җитештерүне сан һәм сыйфат ягыннан яхшыртуның конкрет юллары турында гаять үтемле иттереп сөйләгән идегез. Аннан соң да безнең якларда берничә тапкыр булып киттегез. Инде менә кулга кул тотышып эшләүнең нәтиҗәләрен барлар вакыт та җитте...**

- Бәхеткә, ул нәтиҗәләр бик сөендерерлек. Сезнең район быел бодайны республикада иң күп хәзерләүче район булып тора. Ул гына да түгел, сезнең хуҗалыклар дәүләткә тапшырган бодай сыйфат ягыннан да иң затлысы дияргә мөмкин. Җилемсәлеге 28 проценттан югары булган 7 мең тонна бодайның 5 мең тонналабы сезнең кырлардан җыелуы горурлык түгелмени? Республика буенча хәзерләнгән барлык бодайның 64 процентында җилемсәлелек 23- 28 процент булса, сездә бу күрсәткеч 82 процентка җитә.Ә җилемсәлеге 15 проценттан түбән булган бодай бөтенләй юк. Димәк, уйлап эш иткәндә, фән киңәшләренә колак салып һәм технология таләпләрен үтәп тырышканда бер ел эчендә дә зур нәтиҗәләргә ирешеп була икән бит.

**- Ә бу нәтиҗәләр тагын да яхшырак булырга мөмкин идеме соң?**

- Ничек кенә әле. Һәм монда күп төрле факторларны исәпкә алу мөһим. Иң элек сортларга игътибар итәлергә тиеш. Сезнең районда әлегә бодайның күп сортлары кулланылышта. Төрле - төрле сортларның булуы бер яктан ярый торган эш булса да, алар арасыннан иң кулайларын гына сайлап алу кирәклеге дә бәхәссез. Әйтик, «Энита» бодае талымсызрак булса да, аның уңыш бирүчәнлеге елдан - ел кимүгә барганлыгы күз алдында. Анысы орлыкның репродукциясе кими барган саен табигый да. Ә менә «Приокская», «Красноуфимская- 90», «Люба» сортлары исә кулланылыштагылар арасында әлегә иң ышанычлылардан. Сезнең райондагы сорт сынау участогындагы нәтиҗәләргә дә игътибар итәргә кирәк. **(Ред.: Сорт сынау участогының эш нәтиҗәләре турында аерым сүз булачак әле).**

Әмма бодай сатып күбрәк керем алу турында сүз алып барабыз икән, бодайның күләме белән беррәттән сыйфаты турында да кайтыртырга кирәк. Ә монысы иң элек аның җилемсәлелегеннән һәм сыйфаты буенча кайсы төркемгә керүеннән килеп чыга. Бу яктан быел сезнең район хуҗалыклары хәзерләгән бодайның җилемсәлелеге инде алда әйткәнемчә, чагыштырмача шактый югары, шул исәптән бодайның абсолют күпчелегендә ул күрсәткеч 23 проценттан 28 процентка кадәр. Әмма сыйфат ягыннан беренче төркем таләпләренә җавап бирердәй бодай булмавы кызганыч. Дөрес, быел анысы республикада да юк һәм моның сәбәпләре тирән анализлауны көтә әле. Ә менә җилемсәлелеккә килгәндә, бу күрсәткеч өстендә эшләү җитмәгәнлеге көн кебек ачык. Бер генә мисал. Кузнецов исемендәге хуҗалыктан килгән бодайның җилемсәлелеге бер көнне 22,5 процент чыкты. Әгәр бу күрсәткечне хуҗалыкның үзендә үк үлчәп караган булсалар, аны 23 процентка җиткереп тапшыру чарасын күрерләр иде. Югыйсә бит, әнә шул ярты процент аркасында хуҗалык кассасына һәр тонна бодай өчен йөзәр мең сум акча керми кала бит. Һәм мондый мисалларны тагын бик күп китерергә мөмкин әле. Үзеңдә билгеләмәгәч, элеваторда җилемсәлелекне дөрес ачыкламыйлар дип дәгъва да белдерә алмыйсың. Шуңа күрә бер генә юл кала - хуҗалыкларның үзләрендә бодайның җилемсәлелеген ачыклау лабораторияләре булдыру. Аның җиһазлары һич тә кыйммәт түгел, ә нәтиҗәсе беренче елны ук үзен сиздерәчәк. Хикмәт бит элеваторга озатыла торган бодайның җилемсәлелеген ачыклауда гына түгел, ә бодайның үсеп өлгереп җитү фазаларында әледән әле шушы күрсәткечнең ничек үзгәрүен билгеләп баруда да. Соңгысы шулай ук бик мөһим. Безнәкъ менә шул юнәлештә үткәрә торган тәҗрибәләр төрле сорт бодайның чәчү срокларына карап өлгереш стадияләрендә җилемсәлелеге һәм сыйфат төркеме үзгәреп торуын раслаучы бик кызыклы мәгълүматлар алырга мөмкинлек бирде. Хәтта беренче төркем таләпләренә җавап биргән бодайлар да булды. Менә шуңа күрә дә андый лабораторияләрне һәр хуҗалыкта булдырырга киңәш итәр идек. Сүз уңаеннан әйткәндә, сезнең Мичурин исемендәге хуҗалык җитәкчелеге мондый лабораторияне быел ук алып куярга теләк белдерде дә инде.

**- Аларда бит быел бодайның да алты сортын иктеләр...**

- Шулардан «Московская - 35», «Энита» сортларыннан киләсе елга баш тартырга булганнар инде. Аның каравы, алар быел сынау тәртибендә иккән «Оренбургская - 10» каты бодаен тулысы белән киләсе ел өчен орлыкка калдырачаклар. Орлыгын Әлки районының «Хлебодарский» хуҗалыгыннан минем тәкъдим буенча барып алып кайтканнар иде. 45 гектардан 49,5әр центнер чыккан ул. Каты бодайның бәясен белгән кешегә моның күпмелек булуын чамалавы кыен түгел. Ә каты бодайга ихтыяҗ зур әле. Былтыр ул республикада фәкать 4 мең тонна гына җыелды, токмач промышленносте ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерү өчен кимендә 40 мең тонна кирәк. Шуның 3 мең тоннасын сезнең район бирергә тиеш. Әгәр Мичурин исемендәге хуҗалык быелгы орлыгын тулысынча чәчеп үстерә икән, бу санны артыгы белән капларга мөмкин. Тагын биш - алты хуҗалык шул эшкә специальләшсә дә зыян итмәс иде. Өстәвенә, корылыкка чыдам бу бодайны иртә срокларда чәчү өчен сезнең районда академик Мәҗитов культиваторларын куллану кебек уңай тәҗрибә бар.

**- Шулай да җилемсәлелек һәм сыйфат төркеме күрсәткечләренә тагын бер тапкыр тукталыйк әле.**

- Тел төбегезне аңлыйм мин сезнең. Күп хуҗалык җитәкчеләре һәм агрономнар баш вата ул хакта. Әмма җилемсәлелекнең һич тә элеватор лабораториясендә ясалмавын, ә кырда, аннан соң ындырда, башка төр саклау урыннарында формалашуын онытырга ярамый. Әйткәнемчә, иң элек сортларны сайлап ала белергә кирәк. Менә берничә ел инде Американың «Пионер» фирмасы бодае игелә, сезнең районда да бар ул. Аның гектардан уңышы кайбер сортлар белән чагыштырганда искитәрлек югары түгел, әмма җилемсәлелегенең микъдары һәм сыйфаты ягыннан, бигрәк тә икмәк пешерүдә кулланылыш сыйфатлары буенча күп сортларга биргесез ул.Бары тик аны игү технологиясе таләпләрен генә төгәл үтәргә кирәк. Сүз аны ничек тә иртәрәк чәчү, гектарга 4 миллионнан да артык бөртек кертмәү, 2-3 сантиметрдан да тирәнгәрәк күмдермәү турында бара. Югыйсә артык куе чәчү һәм азотлы ашламаларны чамасыз күп кертү үсемлекләрнең сөрлегүенә төп сәбәп булып тора. Ә сөрлеккән бодайда җилемсәлелек ким дигәндә 5 процентка азрак икәнлеге бәхәссез. Монысы бер. Икенчедән, бодайның төрле сортларын җилемсәлегеннән чыгып үзара кушу турында да уйларга кирәк. Әйтик, җилемсәлелеге 17 проценттан артмаган 100 тонна рядовой бодайга җилемсәлелеге 30 процентлы 8,3 тонна бодай кушу барлык 108,3 тонна бодайны да 18 процент җилемсәлелек белән ашамлык бодае сыйфатында тапшырырга һәм бодайның ике сортын аерым - аерым тапшырганга караганда 13,7 миллион сумнан күбрәк файда алырга мөмкинлек бирә. Әмма мондый исәп - хисапны алдан үткәрү өчен хуҗалыкларның үзләрендә әлеге дә баягы җилемсәлелекне билгеләү буенча мини лабораторияләр булдыру зарур. Монысы бер. Икенчедән, югары уңыш бирүчән, әмма соңрак өлгерә торган «Люба», «Приокская», «Лада» кебек сортларга кушар өчен 10 гына процент булса да иртә өлгерә торган «Пионер», «Красноуфимская - 90» кебек сортларны да игәргә кирәк. Соңгысы быел сездә Мичурин исемендәге һәм «Төрнәс» хуҗалыкларында шактый мул игелде һәм югары уңыш бирде.

Җилемсәлелекындырда да формалаша дигәнгә килгәндә, бодайны җыеп алганнан соң турыдан туры элеваторга озатуга караганда, аны мөмкинлек булганда ындырда тотып тору күпкә файдалы икәнлеге бәхәссез булуын кабатларга туры килә. Бер генә мисал. Сөт - май комбинаты ярдәмче хуҗалыгының турыдан - туры элеваторга китерелгән Америка бодаеның җилемсәлелеге фәкать 21,6 процент килеп, сыйфат төркеме дә икенче генә иде. Ә шуны биш көн тотканнан соң безнең лабораториядә алынган анализлар искитәрлек дәрәҗәдә бөтенләй башка - җилемсәлелек тә 32,3 процент, сыйфат төркеме күрсәткече дә бодайны беренче төркемгә кертерлек. Ә моның акчага күчереп исәпләгәндә аермасы күпме булуын чамалавы кыен түгел. Димәк, хуҗалыкларда ашлыкны урында киптерү, вакытлыча гына булса да саклау мәсьәләсен дә кайгыртырга кирәклеге аңлашыла. Һәм мондый факторлар әле тагын да бар.

**_Бодай турында әйтелгән кадәресеннән дә күп нәрсә аңлашыла торгандыр. Әмма киләчәктә дә бу культураны киң масштабларда игү турында уйлаганда ул факторларның барысын да исәпкә алырга кирәклеге бәхәссез. Чөнки уңыш муллыгы хакына түгелгән күп чыгымнар үзләрен тулысынча акласын да, файда да китерсен өчен бодайның бер үк вакытта югары сыйфатлы да булуы шарт бит әле. Ә никадәр сыйфатлырак бодай сатсак, аның хакы да шулкадәр югарырак бит._**

**Әңгәмәдәш**
**Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.**

СӘЛАМ ӘТЛЕК
№2

# Кешенең үз агачы бар, диләр

Алматы университеты биологлары бу хәлнең чынбарлыкка туры килү-килмәвен тикшергәннәр. Тәҗрибә һәм тикшеренүләр өчен алар авыл җирен сайлаганнар.

Мәсәлән, галимнәр өйрәнүгә билгеләнгән хуҗалыкта алмагачлар яфракларын койганнар, агачлар корый башлаган. Гаҗәп, шул көннәрдә йорт хуҗасы-бакчачының авыруы да билгеле булган.

Үсемлекләр аларга карап үстерүчеләрнең сәламәтлегенә тәэсир итә алалар дигән фикерләр күптән билгеле. Кеше белән агач арасында бәйләнешләр күп кенә халыкларда йола булып кергән.

Шулай да була-кайчак бүлмәдәге гөлләр шиңә яфраклары корый, ә инде берничә көннән йортның хуҗасы да авырып китә. Әгәр дә ул үлә икән, бүлмәдәге гөлләр бөтенләй сула.

Инглизләрдә шундый йола бар: әгәр дә гаиләләрендә берәр кеше үлеп китсә, ул өйдәге гөлләргә кайгы тасе иңдерелә - бу аның кайгысын уртаклашып, аңа ярдәм итү мәгънәсендә була.

Шул изге йоланы үтәмәсәң, гөл якын көннәрдә корып, юкка чыгачак, имеш.

Күп халыкларда баласы туган кеше аның хөрмәтенә агач утырта. Нәтиҗәдә үскәндә үк бала шул «агач»ның үзенеке икәнен белә. Ул аны карап үстерә, суын да сибә, төбен дә йомшарта.

Бер хикәяттә Бенгалия принцы туган җирен, әти - әниләрен калдырып киткәндә, мондый сүзләр әйтә:» Бу агач - минем гомерем. Аны сез яшел яфракта күрсәгез, минем хәлләр әйбәт. Әгәр дә яфраклары саргаеп коела башласа, мин авырып киткән булырмын. Ә инде агач бөтенләй үк корып китсә, мин бу дөнья да булмам.»

Мондый ышанулар әле дә булса үзенең кыйммәтен югалтмый. Кеше гомере һәм агач бер - берсенә өзелмәс җепләр белән бәйләнгәннәр булса кирәк. Кешедән аермалы буларак, агач аннан озаграк яши, тышкы тәэсирләргә бирешми.

Әгәр дә агач корыса, кеше үләргә тиеш булып чыга. Моңа төрле очракларны кертергә мөмкин: авыру, бәхетсезлеккә юлыгу, үтерелү. Бу теория белән фикер йөрткәндә, агач корыса, аның халәте кешегә күчә һәм ул озак та тормый үлеп китә. Теория авторлары моны раслауга шактый мисаллар китерә алалар.

Мәсәлән, Абхазиядә яшәүченең яраткан агачы була. Күршесе аңа зыян салу, үчлек итү максатыннан агачны кисә һәм ул кеше үлә.

Дөньяга мәгълүм шәхесләрнең көндәлекләрендә мондый хәлләрне чагылдырган хикәятләр бар. Мәсәлән, абыйлы - энеле Ричард һәм Густав Кемпенфельд балалары белән агач утыртканнар. Еллар үтә, Король флоты адмиралы Ричард сәяхәттә диңгездә була. Һәм беркөнне Густав абыйсының «агачы» кисәк кенә корып һәлак була. «Димәк, абыйсы белән нәрсә дә булса булган?» Әнә шундый уй килә аның башына. Тиздән кайгылы хәбәр алына. Адмирал сигез йөз кешелек экипажы белән диңгез төбенә киткән. Бу авыр хәл 1782 елның 29 августында була. Шушы көнне Густав абыйсы утырткан агачның корыганын күрә.

Күренекле кинорежиссер Григорий Рошальнең кызы әтисе белән бәйле кызыклы хәлне сөйли:» Әти үз бүлмәсендә күп еллар чәй розасы үстерде. Гомере буена ул аны карап торды. Әти үлүгә, роза да корыды. Югыйсә аны бездә дә бик карап тордык бит».


Кешенең үз агачы булуына ышанырга гына кала. Пушкин да Кырымга баргач Дельвигка мондый эчтәлектәге хат җибәрә: «Өйдән ике генә адымда яшь кипарис үсә иде. Һәр иртәдә мин аның янына бара идем. Минем аңа дуслык хисләре бәйләнгән».

Дөрестән дә, кем агачны шәхес итеп кабул итә, аңа ул агачны кисү җиңел түгел.

Грек философы Порфирий да шул хакта язып калдырган: «Нигә, дигән ул, сарык белән үгезне үтерү - явызлык, имән, чыршы һәм башка агачларның да җаннары бар бит».

(«Шәһри Казан» газетасыннан).

# 76 ЯШЬЛЕК... БӘБИ




***Бәләкәч Седрик... Ул АКШның Алабама штатындагы Мобил шәһәрендә туган. Тугач берничә айдан соң Седрик үсүдән туктаган һәм бүген дә ул, элеккеге кебек, имчәк баласы..Бу уникаль феномен - кешелекнең иң зур серләреннән санала.***

- Минем малайны караган төрледән - төрле табибларның саны өч меңнән дә артып киткәннән соң, мин бүтән өмет калмаганына ышандым, - ди Седрикның әнисе, 94 яшьлек Анна Долимор. Ул тол хатын, 76 яшлек малаен берүзе тәрбияли. Хәер, бу хәлләр менә болайрак башлана.

- Туган чагында Седрик бик матур, таза бала иде, - ди Анна. - Тамакка да таза, тыныч иде. Әтисе белән аңа карап сөенеп туя алмый идек. Әмма алты айдан соң бала үсми башлады. Табибка киттек. Ләкин миңа табиб: «Сезнең үзегезгә дәваланырга кирәк, төрле бала төрлечә үсә инде ул. Берәүләре тиз, икенчеләре акрынрак үсә,» - диде.

Әмма ләкин табибның сүзләре дөреслеккә туры килмәде. Бала авырмаса да гел шул бертөсле кала бирде. Седрикка биш яш тулгач, табиблар да, ниһаять минем сүзгә ышана башладылар. Китте анализлар, китте анализлар! Әмма алар бернинди тайпылыш күрсәтмәделәр - алты айлык бала нинди булырга тиеш - Седрик нәкъ шундый сәламәт бала иде. Протеин блокадасы ярдәм итәр, диделәр - юк! Махсус массаж коткарыр, диделәр - тагын юк! Нинди генә белгечләрнең бусагасын таптамадык ирем белән! Хәтта малайны көнгә ун мәртәбә тартып сузарга кирәк дип әйтүче шарлатаннарны да йөреп чыктык. Файдасы гына булмады. Менә шундый маҗаралардан соң гомеребез буе яшь бала карарга тиешлегебезгә, ниһаять, төшендек.

Башка сыймаслык хәл, әмма факт: әле нибары ун ел элек кенә Америка галимнәре бу хәлнең сәбәбен ачуга ирешәләр: «мәңгелек бәби» феноменын күзәнәкләрнең спецификасы китереп чыгара икән. Бу күзәнәкләр гадәти кешеләрдән картлык «ясый» торган элементларга бирешмиләр. Ә табигатьнең бу көйсезлеген ничек бетерергә? Моңа әлегә җавап таба алганнары юк.

- Ирем белән без бөтен гомеребезне шушы баланы багуга багышладык, - ди Анна һәм елмаеп куя. - Карагыз сез бу нарасыйга! Бигерәкләр дә матур бит инде! Башлы үзе мине әллә кайдан танып ала. Кыен түгел аны каравы. Тәүлегенә 18 сәгать йоклый ул. Минем бөтен туган - тумачаларым үлеп бетте инде. Берүзем калдым. Шушы бала яшәтә бугай мине бу дөньяда, «әни, үлмә, син кирәк миңа», - дип әйтәдер төсле ул нарасый.

Мин үлгәч аның белән нәрсә булыр? Минем балама галимнәр хуҗа булып, аны төрле симпозиумнарда әкәмәт бер җанварны күрсәтеп йөргән кебек күрсәтеп йөртерләр дип куркам. Мин гомерлек түгел бит, аны бер яклаучы табылсын иде.



# БУ КЫЗЫКАЙ КАРТАЕРГА ОНЫТКАН

Роза Фарон 1896 елның 29 маенда туган. Аңа 100 яшь! Әмма аның гәүдәсе кызларныкы кебек, һәм ул һич картаймый, киресенчә көннән - көн яшәрә генә бара.

Врачлар аптырашта. Ялган юк микән биредә дип тикшереп тә карадылар. Әмма бар да дөрес. «Бу хатын таң калдыра. Ул гомерендә беркайчан да бизәнмәгән, пластик операцияләр ясатмаган, шулай да үз яшеннән 70 елга яшьрәк күренә. Аның хәтере әйбәт, баш мие яхшы эшли, уйлый. Гомеремдә очратырга туры килгән иң сәер феномен бу» - диде Генуядагы медиклар коференциясендә доктор Граза.

Ул беренче мәртәбә Роза турында Италия газетасыннан укып белә. Фоторәсемдә - алты оныгы, унбиш оныгының баласы һәм уналты оныгының уртасында утыручы чибәр ханым! Миссис Фарон үзенең 30 яшьлек оныгының баласыннан яшьрәк чырайлы. Аның бавырын, йөрәген һәм кан басымын тикшерүләрдән күренгәнчә, әбекәйнең анализлары кызларыныкыннан ким түгел. Һәм тагын бер гаҗәп нәрсә - хатынның әгъзалары 1960 елдагыдан әйбәтрәк эшли икән. Гүя ки вакыт аның өчен киregә ага.

Картаю проблемаларын өйрәнүчеләр хатынны ярты ел күзәтәчәкләр, аның генетикасы серләрен ачарга тырышачаклар. Врачларны аптырашта калдырган хатын исә үзенең халәтен тәкъдирдән күрә. «Мин бөтен нәрсәне ашыйм, эчәм, тартам. Мине уңайсыз хәлдә калдырган бер нәрсә бар ул да булса балага узудан куркам, йөз яшькә җиткәндә бала табып ятарга оят бит. Һәм шуңа күрә балага узудан саклана торган таблеткалар кабул итәм», - ди ул.

# СОҢ БУЛСА ДА, УҢ БУЛСЫН



Кениядә 79 яшьлек Эвайо Авера малай чагында сөннәткә утыртылмаган булган. Һәм ул авырып үлә, әмма гомере буена авылдашларыннан яшереп килгән серне үзе белән теге дөньяга алып китә алмый. Мәетне юганда сер ачыла. Авыл аксакалы: үлгәннән соң булса да йоланы үтәргә кирәк, дигән таләпне куя.

Өлкәннәр шурасы әгъзасы бергәләп киңәшеп, Эвайоны сөннәтлиләр. «Ничек әлеге көнгәчә шуны белми йөрдек икән без?» - дип аптырыйлар алар.

Бу йоланы үтәүне үз өстенә алган кеше кайгыга чумган тол хатыннан бик зур гонорар: 7 мең Кения шиллингы (130 АКШ доллары), шуның өстенә, үгез һәм әтәч сорый. Иренең сөннәтсез булуын яшереп килгәне өчен авылдашлары аңа ләгънәт укыйлар.

# Сөйләшә торган көзге

Ни чыкса, японнардан чыга. Менә тагын бер нәрсә - сөйләшә торган көзге уйлап тапканнар. Ул ванна бүлмәсенә куела. Хакы да 30 доллар гына. Иртән торып юынып алгач, көзге каршысына килеп бассагыз, ул сезгә: «Син нинди чибәр!» - диячәк. Ә инде аның «серле» көзге икәнен белмичә карап торсагыз: «Нигә миңа күзләреңне акайттың?» - дип җикеренүе дә ихтимал.

# ИКЕ башлы икән - хатынлы булсын

1963 елда Америкада полицейский Людольтер гаиләсендә ике башлы малай дөньяга килә. Аңа Эрик - Карл исемнәре кушалар.

Менә 34 ел инде бу кеше гадәти тормышта яши. Гәүдә бер булса да, башлар еш кына төрлечә фикер йөртә.

Ундүрт яшькә кадәр Эрик - Карл циркта чыгыш ясый. Тамашачыларда бу «артист» гаҗәпләнү генә түгел, курку да уята. Ә соңыннан ул гитарада уйный башлый, Әмма һәр баш җырны үз тавышы белән башкара. Аны төрле илләргә чакыралар, җырларын язалар, пластинкаларын чыгаралар. Соңгы бер ел эчендә генә дә дуэт бер миллион доллардан артык акча эшли.

Дуэтка кызлар да игътибар итә башлый. Кияүгә чыгарга теләүчеләр дә табыла. Күпләр Эрик - Карлның ике хатыны булырга тиеш дип фикер йөртә.

# ГРИПП ЮЛГА ЧЫКТЫ

Медиклар хәбәр итүенчә, октябрь азакларында Руссия халкын грипп аяктан егачак.

Ләкин бу чир тагын бер ай буе тавыш - тынын чыгармыйча тора дигән сүз түгел. Инде кайберәүләр, бигрәк тә балалар, чирләп алырга өлгерде.

Табибларның күп еллык күзәтүләреннән күренгәнчә, салкын тидерү, ОРЗ белән авыру нәкъ менә көзнең беренче яртысына туры килә. Чөнки көннәр салкыная, өйләргә әле якмыйлар. Эш урыннарындагы, өйдәге, мәктәптәге, ясле - бакчалардагы суыклык, дымлылык шәһәр кешесенең чирләшкә организмына бик тә тиз тәэсир итә.

Шуңа күрә түбәндәге киңәшләрне колагыгызга киртеп куегыз: иң беренче чиратта, артык туңмаска; тиешенчә тукланырга, витаминнар ашарга; мышык - пышык борын тарткан, төчкергән кеше белән аралашмаска; хәлсезлек сизсәң, эшкә бармыйча, берничә көн өйдә утырырга.

Безнең илдә инде егерме еллап А һәм Б грипплары йөри икән. Узган ел прививка ясаткан кешеләрнең 92 процентына грипп тимәгән (ә калганнары бик җиңел кичергән).

Белгечләр беренче чиратта йөрәк чирле кешеләргә, ВИЧ инфекциясе йөртүчеләргә, шикәр диабеты белән авыручыларга, балаларга һәм 65 яшьтән узган кешеләргә гриппка каршы прививка ясату мәҗбүри дип баралар. Прививканы, табиб белән киңәшкәннән соң, октябрь азакларына таба ясатырга кирәк.

(«Татарстан яшьләреннән»).



Таныш булыгыз: рәсемдә Чулпан урта мәктәбе директорының уку - укыту эшләре буенча урынбасары Исхак Мингалимов. Исхак Минхәерович әлеге мәктәптә бөрөзлексез 36 ел эшли, шуннан соңгы 23 елын уку - укыту эшләренә җитәкчелек итә.

Н.АЗИЗОВ фотосы.

## ПЕЛӘШ БАШЛЫ КИЯҮ

*Шулай да була*

Ир белән хатынның аерылышуы төрле сәбәпләрдән килеп чыга. Иранда матур гына бер парның никахы өзелүгә ... пеләш баш сәбәпче булган.

Таһран судына кергән гаризада гүзәл ханым иренең мәкерлеген гафу итә алмавы турында яза. «Ул миңа әшәке ялган ярдәмендә өйләнгән булып чыкты. Мин аның башының бильярд шарыдай шома икәнлеген белмәдем. Чәчләре юклыгын бик зиннәтле парик белән яшергән», - дип аңлата ханым.

Шунысы кызык, туйдан соң берничә ай үткәч кенә ачыла бу ялган. Бер кичәдә ыгы - зыгы вакытында бәхетсез ир егыла, шунда башыннан паригы да төшә (начар беркетелгән булган күрәсең).

Дәгъвачы хатын никахны өзүне генә түгел, ә мораль зыян ясаган өчен 140 миллион риал акча түләүне дә таләп итә. Иренең пеләш булуын ул бик тә авыр кичергән һәм озак вакыт һушына килә алмаган.

## МОДА ТУРЫНДА

1. Мода XX гасырга кадәр төрле катлам кешеләре ничек киенергә тиешлеген билгеләүче закон ролен үтәде. Югарырак катламдагы кешенең киеме җайсызрак булырга, аның физик эш эшләмәгәнлеге киемендә чагылырга тиеш. Борынгы римлыларда ирләр кия торган өске кием - тоганың озынлыгы 5 метрга җиткән; Француз короле Карл IXның хатынының күлмәге 24 метр, урта гасыр феодалларының туфлие 60 сантиметр озынлыкта булган. Яңарыш эпохасында бикә - ханымнар 25 килограммлы күлмәкләр киеп йөргәннәр.

2. Беренче бөтендөнья сугышы модага революция ясады. Югары катламдагы хатын - кызлар хезмәтчеләрдән баш тарталар, җәмәгать транспортыннан файдалана башлыйлар. Итәкләр, чәчләр кыскара, зур эшләпәләр кечкенәләре белән алмаштырылалар.

3. Генрих Плантагент аяк табанындагы шешне каплар өчен зур озын башлы итек уйлап таба. Ямьсез аяклы Карл VIII озын итәкле камзулны модага кертә. Людовик XIV пеләшен парик астына яшереп йөри. Аңардан күреп, министрлар, патша сараендагы хатын - кызлар парик кия башлыйлар. Эдуард VII бервакыт, яңгырда калып, чалбарның кире ягын әйләндереп кия һәм манжетлы чалбар уйлап табучы исемен ала. Павиядәге сугыш вакытында Франц I нченең башы яралана һәм аңа чәчен, сакалын кырырга туры килә. Нәтиҗәдә, Франциядә сакал бөтенләй юкка чыккан.

4. 1773 елда европалылар Галлея кометасын күзәткәннәр, шуннан соң «Аля комета» прическасы модага кергән. XVIII гасырда Парижга беренче тапкыр мөгезборын алып кайту вакыйгасы мөгезле эшләпә модасын кертә.

1922 елда инглиз археологлары фиргавен төрбәсе тапканнан соң, Европаның модалы хатын - кызлары «Египтянка» прическасын йөртә башлыйлар.

5. Королева Екатерина Медичи патша сараендагы хатын - кызларга билләрен 33 сантимердан юанайтмаска боерган.

6. 1880 елда Оксфорд университеты ишкәкчеләре кулга бәйли торган махсус бәйләвечләрен муеннарына бәйлиләр - галстук модага керә.

7. XVI гасырда Италиядә һәм Франциядә аристократларның аяк киемендәге агач аслыкның биеклеге 25 сантиметрга җитә; тора - бара үкчәнең формасы үзгәрә, Мари - Антуанетта вакытында ул 12 - 15 мм га кадәр нечкәрә.

8. Нейлон җитештерә башлау бик нечкә, калынлыгы 8 денье булган оеклар җитештерергә мөмкинлек бирә (кеше чәченең уртача калынлыгы 50 денье).

9. Рус императоры Николай IIнең бертуганының кызы Ирина Йосыпова дөньяда беренче аристократ - манекенчы (күргәзмәдә кием күрсәтүче) була. Ире Феликс Йосыпов белән Парижга күчеп киткәч, ул үзенең «Ирфе» (ягъни Ирина, Феликс) модалар йортын ача һәм үз кулы белән эшләгән киемнәрен үзе күрсәтә.

10. XIX гасырның икенче яртысында король тегүчесе Шарль Фредрик Ворт беренче тапкыр үзенең модельләрен күрсәтү өчен манекенчылардан файдалана. Моңа кадәр модельләр бюстларда гына күрсәтелгән.

11. 1924 елда Француз модельеры Жан Пату Америка Кушма Штатларында югары катламнан 6 яшь кызны сайлап алып, модельләр күрсәтү сәнгатенә өйрәтә. Аларны Парижга алып килеп шоу үткәрә һәм зур уңыш казана. Баштарак манекенчы ролен яхшы тегүчеләр башкарган. Пату уйлап тапкан бу һөнәр хәзер иң дәрәҗәлеләрдән санала.

12. 1983 елның 19 - 21 сентябрендә Дублинда «Паркс отеле»нда үткәрелгән модалар күрсәтү вакытында манекенчылар Роберта Браун һәм Лоррейн Маккорт һәркайсы 114,4 километр юл үтәләр.

13. XIX гасырның танылган артисты Сара Бернар - ирләр чалбары кияргә йөрәге җиткән беренче хатын - кыз.

14. Инглиз аристократлары гольф уйнау өчен иң модалы спорт аяк киемен «Стило мэтчмейкерс интернешнл» фирмасыннан алалар. Аның бер пары 13700 доллар тора. Бу аяк киеменең эчлеге чәшке тиресеннән алтын белән каймаланган һәм якут очлыклы шиплары бар.

(«Юлдаш» газетасыннан).


# КОТЛЫЙБЫЗ!

*Кадерле кешебез **Рәфис Рафик улы Хәмзинны** чын күңелдән юбилее белән котлыйбыз. Аңа эшендә уңышлар, гаиләсендә тигезлек, тынычлык телибез.*

*Синең тормыш юлларыңда*
*Очрамасын киртәләр*
*Гел шатлыклар, гел бәхетләр*
*Алып килсен иртәләр.*

*Күңел күгең һәрчак аяз булсын,*
*Килмәсеннәр сагыш - борчулар*
*Ныклы сәламәтлек юлдаш булсын,*
*Аннан кадерлерәк нәрсә бар!*

***Иң изге теләкләр белән әтисе , әнисе һәм туганнары.***

## Белдерүләр

**САТАБЫЗ**
**Универмаг бүлекләрендә киң ассортиментта бәясе төшерелгән товарлар сатыла.**

* * *

**Ашыгыч рәвештә 1976 елгы ВАЗ - 2101, кыйммәт түгел**. Тел.: 2 - 15 - 06, 8 дән 14.00 гә кадәр (якшәмбедән тыш).

* * *

**Ашыгыч төстә «Москвич - 2140», кыйммәт түгел.** Якты Күл авылында И.Г.Фәйзуллинга яки 2 - 13 - 13 телефоны буенча мөрәҗәгать итәргә.

* * *

**Силикат кирпеч һәм өстәмә түләп шифер.** Тел.: 5 - 21 - 22. Таныклык № 268 - 97.

* * *

**«Хыял» бакчачылык җәмгыятендә дача участогы.** Тел.: 2 - 12 - 52, (18 сәг. соң).

* * *

**Шламка авылында йорт, 60 сутый бакчасы бар, табигый газ үткәрелә.** Шламка авылында Мөхәммәтҗанов Шамилгә мөрәҗәгать итәргә.

* * *

**Шәһәр үзәгендә 1 бүлмәле фатир**. Тел.: 5 - 20 - 00.

* * *

**Сәүдә базасында түмәрләп һәм ваклап свежий балык. Килограммының бәяләре:**

**- горбуша - 10500 сум.**
**- треска - 8900 сум.**
**- комбала - 8200 сум.**
**- минтай - 8200 сум.**
**- навага - 7700 сум.**
**«Тоник» эчемлеге - 3650 сум.**

* * *

**Ашыгыч рәвештә әйбәт хәлдәге «Москвич - 2140», бәясе - 3,5 млн. сум, сатулашырга мөмкин.** Самара өлкәсе, Кошки районы, Ермаково авылында Еремеев Вячеславка мөрәҗәгать итәргә, тел.: 4 - 52 - 96, кич белән.

## Кыйммәтле дарулар.

***Таблеткада мумие - ашказаны язвасын, бавыр, бөер, сидек куыгы, колит, гастрит авыруларын дәвалый.***

***Женьшень - неврастения, йөрәк неврозы, нервлы борчулар, баш авыруы вакытында кулланыла.***

***Магнит билбавы, япмасы, Караваев бальзамы, андыз ( девясил) үләне, алтын тамыр.***

***Эллир ( майлы эретмә) - геморрой, гинекологик, тире авыруларын, остеохондроз, ревматизм, тропик язва, фурункулдан шифалы. Бу препаратларны сез район үзәк шифаханәсеннән 25 һәм 26 сентябрь көнне 9.00 дан 13.00 га кадәр сатып ала аласыз.*** Лицензия - 00458.

## *Идел Буе региональ наркология үзәге*

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.* **Табиб М.Б.Багрянцев.**

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга көннәрендә, 26 сентябрь, 10 октябрьдә көндезге сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.



БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2336 данә.